ЧӘРШӘМБЕ
3
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 27 (6749)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һӘМ КАЗАН ШӘһӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘһӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ДОН ФРОНТЫ ШТАБЫ, 2 ФЕВРАЛЬ 43 ЕЛ, 18. 30.

МОСКВА,

ССР Союзының кораллы көчләре Верховный Баш Командующие иптәш СТАЛИНГА

Хәрби донесение № 0079/оп

Дон фронты гаскәрләре, Сезнең приказыгызны үтәү йөзеннән, 1943 нче елның 2 нче февралендә 16 сәгать 00 минутта ДОШМАННЫҢ СТАЛИНГРАД РАЙОНЫНДА ЧОЛГАНЫП АЛЫНГАН ГРУППАСЫН ТАР-МАР ИТҮНЕ һӘМ ЮК ИТҮНЕ ТӘМАМЛАДЫЛАР.

22 дивизиядән: немецларның 44 нче, 71 нче, 76 нчы, 79 нчы, 94 нче пехота дивизияләреннән, 100 нче җиңел пехота дивизиясеннән, 113 нче, 376 нчы, 295 нче, 297 нче, 305 нче, 371 нче, 384 нче, 389 нчы пехота дивизияләреннән; моторлаштырылган 3 нче, 29 нчы һәм 60 нчы дивизияләрдән; 14 нче, 16 нчы һәм 24 нче танк дивизияләреннән; румыннарның 1 нче кавалерия һәм 20 нче пехота дивизияләреннән торган 11 нче армия корпусы, 8 нче армия корпусы, 14 нче танк корпусы, 51 нче армия корпусы, 4 нче армия корпусы, 48 нче танк корпусы бөтенләй юк ителде һәм бер өлеше плен алынды.

Болардан тыш көчәйтү частьларыннан түбәндәгеләр юк ителде:

а) баш командование резервының 42 нче, 44 нче, 46 нчы, 59 нчы, 61 нче, 65 нче, 72 нче артиллерия полклары; баш командование резервының 1/97 нче артиллерия полкы, 43 нче, 639 нчы, 733 нче, 856 нчы, 855 нче, 861 нче атиллерия дивизионнары; 243 нче штрум орудиеләре дивизионы; баш командование резервының алты көпшәле минометлар белән коралланган 2 нче һәм 51 нче миномет полклары; үзләренең аерым частьлары башка фронтларда хәрәкәт итә торган төрле полкларның 9 нчы, 12 нче, 25 нче, 30 нчы, 37 нче, 91 нче зенит дивизионнары.

б) 45 нче, 71 нче, 294 нче, 336 нчы, 652 нче, 672 нче, 685 нче, 501 нче аерым сапер батальоннары һәм аерым рәвештә, номерсыз бер сапер батальоны.

в) 21 нче, 40 нчы, 540 нчы, 539 нчы аерым төзү батальоннары.

г) 6 нчы элемтә полкы һәм, ихтимал, 594 нче элемтә полкы.

д) 7 нче һәм 28 нче артиллерия инструментлары разведкасы (АИР) дивизионнары.

е) күп күпер колонналары һәм хезмәт күрсәтүче башка частьлар.

91.000 нән артык пленный алынды, шул исәптән 2.500 дән артык офицерлар һәм 24 генерал, шулардан генерал-фельдмаршал—1, генерал-полковниклар—2, калганнары генерал-лейтенантлар һәм генерал-майорлар.

Дошманның чолганып алынган гаскәрләре бөтенләй бетерелгәнлектән СТАЛИНГРАД шәһәрендә һәм СТАЛИНГРАД районында сугыш хәрәкәтләре тукталды.

Трофейларның санын алу дәвам итә.

Верховный Баш Командование Ставкасы вәкиле Артиллерия Маршалы **ВОРОНОВ.**

Дон фронтының хәрби совет члены генерал-майор **ТЕЛЕГИН.**

Дон фронты гаскәрләре командующие генерал-полковник **РОКОССОВСКИЙ.**

Дон фронтының штаб начальнигы генерал-лейтенант **МАЛИНИН.**

Верховный Баш Командующийның Дон фронты гаскәрләре буенча приказы

ДОН ФРОНТЫ.

Верховный Баш Командование ставкасы вәкиле Артиллерия Маршалы иптәш ВОРОНОВКА.

Дон фронты гаскәрләре Командующие генерал- полковник РОКОССОВСКИЙГА.

Сталинград янында чолганып алынган дошман гаскәрләрен бетерүне уңышлы төгәлләвегез белән Сезне һәм Дон фронты гаскәрләрен котлыйм.

Бик яхшы сугыш хәрәкәтләре өчен Дон фронтының барлык сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына рәхмәт игълан итәм.

Верховный Баш Командующий И. СТАЛИН.

Москва, Кремль.
2 февраль 1943 ел.

МОСКВА, КРЕМЛЬ,

Дәүләт Оборона Комитеты Председателе иптәш СТАЛИНГА

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Героик Кызыл Армиянең гүзәл уңышлары белән, шулай ук «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзелешенә 100 миллион сум акча җыйган орденлы Татарстанның колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына Сезнең котлау телеграммагыз һәм Кызыл Армиянең рәхмәт белдерүе белән рухланган безнең республикабызның комсомолецлары һәм яшьләре, пионерлары һәм мәктәп балалары сугыш самолетлары төзелешенә үзләренең саклык акчаларыннан кыска срок эчендә өстәмә рәвештә 9 миллион сум тупладылар. Средстволар туплау дәвам итә.

Татарстанның комсомолецлары һәм яшьләре ватанны героик саклаучыларга бүләк итеп, моннан элек үзләренең саклык акчаларына сугыш самолетларының 3 эскадрильясен төзегәннәр иде.

Халык үчен алучы партизаннар өчен республиканың яшьләре 1.000 пар итек һәм ботинка, 1.000 пар киез итек, 1.000 куртка, 1.000 пар җылы оекбаш, 1.000 дәнә мех жилет, 1.000 свитер, 1.000 данә колакчын бүрек, 15.000 данә кисет һәм кулъяулык, 20 данә кул һәм кесә сәгате, 1.000 пар чалбар һәм гимнастерка, 1.000 пар эчке белье, 500 килограмм май, 1.000 килограмм пряник, 300 килограмм конфет һәм шоколад, 1.000 килограмм какланган ит һәм башка продуктлар җыеп җибәрделәр.

Республиканың комсомолецлары һәм яшьләре Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә производство программасын срогыннан элек үтәү өчен, язгы чәчүгә үрнәк төстә әзерләнү, фронтка ярдәмне тагын да көчәйтү өчен социалистик ярышны җәелдерәләр. ВЛКСМ комитеты секретаре иптәш Котова булган заводта комсомолецлар һәм яшьләр бер дивизияне коралландыру өчен эш вакыты булмаган сәгатьләрдә эшләп, планнан тыш продукция бирергә йөкләмә алдылар. Республикадагы предприятиеләрнең күпчелеге бу инициативага кушылды һәм ул зур патриотик эш сыйфатында үткәрелә.

Халык средстволарына төзелгән сугыш машиналары һәм кораллар безнең данлыклы танкистларыбызга һәм очучыларыбызга, пехотачыларыбызга һәм артиллеристларыбызга, партизаннарга һәм партизан хатын-кызларыбызга дошманны юк итүгә ярдәм итсен, безнең туган җиребездә кан эчүче фашист этләрнең барлык җинаятьләре өчен җәза бирү сәгатен якынайтсын.

Сезгә, кадерле атабыз, остазыбыз һәм дустыбызга бөтен күңелебездән озын гомер һәм сәламәтлек телибез.

ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты Секретаре—Б. ЛУЦКЕР.

КАЗАН,

ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитетының секретаре иптәш ЛУЦКЕРГА

СУГЫШ САМОЛЕТЛАРЫ ТӨЗҮ ӨЧЕН ӨСТӘМӘ РӘВЕШТӘ 9 МИЛЛИОН СУМ АКЧА ҖЫЙГАН ТАТАРСТАН АВТОНОМИЯЛЕ СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ КОМСОМОЛЕЦЛАРЫНА, ЯШЬЛӘРЕНӘ, ПИОНЕРЛАРЫНА һӘМ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА МИНЕМ КАЙНАР СӘЛАМЕМНЕ һӘМ КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ РӘХМӘТЕН ТАПШЫРЫГЫЗ.

И. СТАЛИН.

Соңгы сәгатьтә

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР НЕМЕЦ ФАШИСТЛАРЫНЫҢ СТАЛИНГРАД РАЙОНЫНДА ЧОЛГАНЫП АЛЫНГАН ГАСКӘРЛӘРЕН БЕТЕРҮНЕ ТУЛЫСЫНЧА ТӨГӘЛЛӘДЕЛӘР

Бүген, 2 нче февральдә, Дон фронты гаскәрләре немец фашистларының Сталинград районында чолганып алынган гаскәрләрен бетерүне тулысынча төгәлләделәр. Безнең гаскәрләр Сталинградтан төньяктарак чолганып алынган дошманның каршылык күрсәтүен бастырдылар һәм аны коралын ташларга мәҗбүр иттеләр. Сталинград районында дошманның каршылык күрсәтә торган соңгы үзәге сытып ташланды. 1943 нче елның 2 нче февралендә Сталинград янында булган тарихи сугыш безнең гаскәрләрнең тулы җиңүе белән тәмам булды.

Соңгы ике көн эчендә плен алынучылар саны 45.000 гә артты, ә 10 нчы январьдан 2 нче февральгә кадәр булган сугышлар вакытында безнең гаскәрләр барлыгы 91.000 немец солдатын һәм офицерын плен алдылар.

2 нче февральдә безнең гаскәрләр 11 нче армия корпусы командиры, Сталинградтан төньяктарак чолганып алынган немец гаскәрләре группасы командующие генерал-полковник ШТРЕККЕРНЫ һәм аның штаб начальнигы генштаб полковнигы ГЕЛЬМУТ РОССКУРТНЫ плен алдылар.

Болардан тыш 1 нче һәм 2 нче февральдә немецлар армиясенең түбәндә әйтелгән генераллары плен алынды: 1) 8 нче армия корпусы командиры генерал-полковник ВАЛЬТЕР ГЕЙТЦ, 2) 76 нчы пехота дивизиясе командиры генерал-лейтенант фон РОДЕНБУРГ, 3) 113 нче пехота дивизиясе командиры генерал-лейтенант фон ЗИКСТ АРМИН, 4) 24 нче танк дивизиясе командиры генерал-лейтенант фон ЛЕНСКИ, 5) 389 нчы пехота дивизиясе командиры генерал-майор МАРТИН ЛЯТМАН, 6) Сталинградның үзәк өлешеннән көнбатыштарак чолганып алынган немец гаскәрләре группасы

(Ахыры 4 нче биттә).

«Математик Лобачевский» исемле пароходның командасы ремонт эшендә Аракчино затонында беренче урынны алды. Рәсемдә: алгы планда—капитанның беренче ярдәмчесе стахановчы В. А. Максимов.

Б. Невзоров фотосы.

КЫЗЫЛ АРМИЯГӘ—СУГЫШ САМОЛЕТЛАРЫ

1 МИЛЛИОН 200 МЕҢ СУМ

Иптәш Сталинның приказы унае белән Балтач районының барлык колхозларында да күп кешелек митинглар булып үтте. Митингларда катнашучы колхозчылар бу тарихи приказга җавап итеп самолетлар эскадрильясе төзү фондына акча җыю турында карарлар кабул иттеләр.

Киров исемендәге колхоз члены, кызылармеец семьясы иптәш Медведева митингта ук самолетлар эскадрильясе төзү өчен 2.000 сум акча бирде. Хезмәт инвалиды Иван Павлов 1.500 сум бирде. Берничә көн эчендә «Көрәш» колхозында самолетлар эскадрильясе төзү фондына 42.000 сум, «Марс» колхозында 48.263 сум акча җыеп тапшырылды.

Үзенең өч улын ватан сугышы фронтына озаткан «Марс» колхозы члены иптәш Хәйретдинов танклар колоннасы төзүгә 1.000 сум акча биргән иде. Ул самолетлар эскадрильясе төзүгә тагын 800 сум акча бирде.

1 нче февральдә самолетлар эскадрильясе төзү фондына район буенча барлыгы 1 миллион 200 мең сум акча җыелды. Акча җыю дәвам итә.

Ф. Г.

ПАТРИОТЛАР ВЗНОСЫ

Баулы районының «Кызылармеец» колхозы патриотларын бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның приказы тагын да ныграк рухландырды. Колхоз члены иптәш Җәләлетдинов самолетлар төзү өчен тагын 13.000 сум акча кертте. Аның бу патриотик чыгышына башка колхозчылар да кушылдылар һәм гомуми җыелышта өстәмә рәвештә, тагын 30.000 сум акча тапшырырга карар бирделәр. Бу сумма хәзер тулысынча җыеп тапшырылды инде. Колхоздан элек тә 33.000 сум акча тапшырылган иде.

И. МИҢЛЕБАЕВ.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

ЛАЕКЛЫ КАДРЛАР

Колхоз производствосының байтак кына кадрлары ватан сугышы фронтларына киттеләр. Алар урынын яңа кешеләр алмаштырды. Бу кадрлар арасында күп кенә хатын-кызлар бар.

Эшкә яңа күтәрелгән кадрларны тәрбияләү, аларга практик булышлык итү буенча политбүлеккә, үзенең оешуының беренче көннәреннән ук, җитди шөгыльләнергә туры килде. Кадрларның эш төренә карап төрле курслар үткәрелде. Курс-семинарлар оештырылды. Эш барышында тәҗрибәләрне алмашу өчен еш кына киңәшмәләр үткәрелде.

Хатын-кыз кадрларның күбесе үзләренә йөкләтелгән бурычны намус белән үтиләр. Менә тракторчы Нәфисә иптәш Имамиева. Ул тракторчылар арасында социалистик ярышны җәелдерүдә инициаторлардан берсе. Үзенең үрнәкле эше белән ул иптәшләренә ярдәм итте. Үз сменасында 300 гектар җир сөрергә йөкләмә алып, аны арттырып үтәде, күп кенә килограмм ягулыкка экономия ясады. Аның үрнәгендә Мөхәмәтҗанова Хәтимә еллык эш планын 250 гектар урынына 360 гектар итеп үтәде, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы тарафыннан мактау грамотасы белән бүләкләнгән Динмөхәметова Гаян иптәш тә еллык планын 200 процентка арттырып үтәп, 335 килограмм ягулыкка экономия бирде.

Колхоз җитәкчелеге постына күтәрелгән хатын-кызлар да үзләренең лаеклы кадрлар булуын практик эшләрендә күрсәттеләр. «Память Ленина» колхозы председателе Шишова, «Новая жизнь» колхозы председателе Черешных иптәшләр үзләре җитәкчелек иткән колхозларда 1942 нче елны хуҗалык эшләрен вакытында башкаруны оештырдылар.

Хәзерге чорда колхозчылар арасында политик-масса эшләрен тиешле югарылыкта оештыруның аеруча әһәмияте бар. Бу эшне агитаторлар башкаралар. Шуның өчен политбүлек агитатор кадрлар әзерләү эшенә дә зур игътибар бирә. Агитаторларның күпчелеге турыдан-туры колхоз производствосыннан күтәрелделәр. Аларны тәрбияләү, агитаторлык сәнгатен үзләштерүдә практик булышлык күрсәтү өчен курс-семинарлар еш кына үткәрелә. Халыкара хәлләр һәм башка темаларга лекцияләр үткәрелә.

Игеннәрне урып-җыю вакытында, дәүләткә ашлык тапшыруда һәм башка эшләрдә агитаторлар гаять зур роль уйнадылар. «Новая жизнь», «Победа», «Батыр кул» колхозы агитаторларының үрнәкле эшләрен аеруча күрсәтеп үтәргә кирәк. Бу колхозларда барлык эшләр уңышлы үтәлде.

Ләкин шуны әйтергә кирәк, яңа күтәрелгән кадрларга практик булышлык итү, аларның политик һәм техник белемнәрен күтәрү буенча политбүлеккә күп эшләргә кирәк әле. Политбүлек бу бурычны, һичшиксез, үтәр.

Ә. ЮСИПОВ,
Бондюг МТС ы политбүлек начальнигы.

КОМСОМОЛ ҖИТӘКЧЕЛЕК ИТКӘН УРЫНДА

Наласа авылы (Арча районы) комсомол оешмасы уку өенең эшен яхшырту буенча җитди рәвештә шөгыльләнә. Бу уку өендә кичләрен һәркөнне кызу эш кайный. Анда колхозчылар, колхозчы хатын-кызлар һәм укучы балалар җыелалар.

Агитаторлар колхозчыларга партия, хөкүмәт карарларын, ватан сугышы хәлләрен, Совет Информбюросы белдерүләрен аңлаталар. Кычкырып газеталар укыйлар. Әледән-әле күмәкләп радио тыңлаулар оештырыла. Стена газеталары регуляр рәвештә чыгарыла. Бу чаралар барысы да уку өенең планы буенча алып барылалар.

Биредә драмтүгәрәк тә яхшы гына эшләп килә. Аның тарафыннан айга 3 тапкыр спектакль һәм концерт үткәрелә. Әле күптән түгел генә булган концерттан җыелган акчадан 1.200 сум танклар колоннасы төзү фондына һәм 1.000 сум фронттагы сугышчыларның балаларына бүләк алу өчен тапшырылды.

Уку өе (мөдире иптәш Кәримова) тирәсенә киң актив тупланган. Алар уку өе тарафыннан үткәрелә торган чараларда актив катнашалар.

Н. ХӘЙРУЛЛИН.

ЯРДӘМЧЕ ХУҖАЛЫКЛАРНЫҢ ҮРНӘК ЭШЛӘҮЛӘРЕ ӨЧЕН

(Ярдәмче хуҗалыклар работникларының өлкә киңәшмәсеннән).

Татарстан АССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты, шушы көннәрдә, предприятиеләр каршындагы ярдәмче хуҗалыклар работникларының өлкә киңәшмәсен үткәрделәр. Киңәшмәнең көн тәртибе буенча «Ярдәмче хуҗалыкларның 1942 нче елдагы эш йомгаклары һәм 1943 нче елгы бурычлар турында» докладны Совнарком председателе урынбасары иптәш Шибдин ясады.

—Предприятиеләрдәге һәм учреждениеләрдәге ярдәмче хуҗалыклар,—диде иптәш Шибдин,—хезмәт ияләре өчен өстәмә азык продуктлары булдыруда гаять мөһим чыганак булып торалар. Хәзер мондый хуҗалыклар бик күп оештырылды. Эре предприятиеләр карамагына, хөкүмәт карары буенча, махсус совхозлар бирелде. Бүгенге көнне Татарстанда 632 оешманың үз ярдәмче хуҗалыклары оештырылды.

Алга куелган җитди бурычларны тулысынча аңлаган урыннарда ярдәмче хуҗалыклар яхшы эшлиләр, зур уңыш алалар, хуҗалыкны һаман ныгыталар, үстерәләр (совхоз директоры Никифоров булган Н-че завод, төзү тресты, баш инженеры иптәш Корнеев булган завод, Васильево урман комбинаты һ. б.).

Ләкин республикабыздагы байтак кына ярдәмче хуҗалыкларның эшләре һаман да әле канәгатьләнерлек рәвештә алып барылмый. 1942 нче елның йомгаклары моны ачык күрсәтәләр. Ярдәмче хуҗалыкларда, гомумән алганда, уңыш һаман да түбән әле. Мәсәлән, «Спартак» комбинаты, киез итек-фетр фабрикасы, Н-че завод, Трампарк һ. б. узган елны бәрәңгене гектардан нибары 7—30 центнер гына алдылар. Күп кенә ярдәмче хуҗалыклар һәм совхозлар узган елны чәчү планын (аеруча бәрәңге һәм яшелчә буенча) үтәмәделәр. Парник-теплица хуҗалыгына тиешенчә әһәмият бирелми. Терлекчелекне үстерү планы да үтәлми.

Мондый хурлыклы хәл—ярдәмче хуҗалык директорларының, ОРС начальникларының, предприятие җитәкчеләренең үзләренә тапшырылган гаять мөһим бурычны үтәүгә җавапсыз караулары нәтиҗәсе. Моңа кискен рәвештә чик куелырга тиеш. Эшчеләрне тәэмин итү эшен езүчеләрне каты җавапка тартырга кирәк.

1943 нче елгы язгы чәчүгә әзерләнү һәм аны үрнәк төстә үткәрү—бүгенге көннең иң сугышчан бурычы булып тора. Быел ярдәмче хуҗалыкларда сабан ашлык чәчү планы 20.579 гектар (шулардан, бәрәңге—5.079,7 гектар, яшелчә—2.505,8 гектар) һәм башка оешмалар буенча—10.527 гектар (шулардан, бәрәңге—3.259 гектар, яшелчә—1.572 гектар) күләмендә билгеләнгән. Бу план тулысынча үтәлергә һәм ярдәмче хуҗалык кырларыннан югары хәрби уңыш алынырга тиеш.

Күп кенә ярдәмче хуҗалыкларда язгы чәчү өчен кирәкле орлык әзерләү һәм аларны чистартып, тулы кондиция хәленә китерү эшләре төгәлләнмәгән әле. Бу эшләрне кыска вакыт эчендә төгәлләргә кирәк. Орлыкның дәүләттән бирелүен көтеп торырга һич тә ярамый. Һәрбер хуҗалык, һәрбер предприятие чәчү өчен кирәк булган барлык орлыкны үз инициативасы белән әзерләргә тиеш. Бәрәңге орлыгы өчен аеруча бәрәңге күзәнәге кисеп әзерләүне кызурак һәм кыюрак темплар белән алып барырга кирәк. Югыйсә бу эш күпчелек урыннарда башланмаган да әле. Ашламалар әзерләү, кырга тирес ташу, кар тоту, авыл хуҗалыгы машиналарына һәм инвентарена ремонт ясауны үз вакытында төгәлләү, кирәкле кадрлар әзерләү—болар барысы да ярдәмче хуҗалыклардан быел югары уңыш алуга, фронт өчен корал коючы хезмәт ияләрен өстәмә рәвештә азык продуктлары белән тәэмин итүдә бүгенге көннең практик чаралары булып торалар.

Ярдәмче хуҗалыкларда парник-теплица хуҗалыгын үстерү, киңәйтү, терлекчелек санын һәм продуктлылыгын арттыру планнары быел һичбер сүзсез үтәлергә тиешләр.

Барлык ярдәмче хуҗалыкларның, предприятиеләргә беркетелгән совхозларның, ОРС ларның эшләрен үрнәк төстә сештырүга, бу турыда Татарстан Совнаркомы һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты карарын тулысынча үтәүгә, 1943 нче елгы язгы чәчү кампаниясен большевикларча үткәреп югары хәрби уңыш алу эшенә барлык көч мобилизацияләнергә тиеш.

Доклад буенча фикер алышуларда Н-че завод совхозы директоры Никифоров, Зеленодольск респторгының ярдәмче хуҗалыгы директоры Яценко, Н-че заводның ярдәмче хуҗалыгы директоры Кадиров, профессорлардан Сырнев, Лупинович, 2 нче номерлы совхоз директоры Старков, Наркомзем агрономы Шәһидуллин, Мединститутның ярдәмче хуҗалыгы директоры Костышев һ. б. иптәшләр—барлыгы 21 кеше чыгып сөйләде. Алар үзләренең чыгышларында 1942 нче елдагы эш йомгаклары турында, ярдәмче хуҗалыклар алдында быел торган бурычлар, уңышлы тәҗрибәләрне башкаларга күчерү, эштә булган кимчелекләрне ничек җиңү юллары турында сөйләделәр.

Киңәшмәдә ВКП(б) Өлкә Комитетының секретарьлары Бәдретдинов һәм Варламов, ВКП(б) шәһәр комитеты секретаре Әхмәдуллин иптәшләр чыгып сөйләделәр. Алар ярдәмче хуҗалыкларны үстерү, ныгыту өлкәсендә булган җитешсезлекләрне нык тәнкыйть астына алып, алар алдына практик бурычлар куйдылар, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, ярдәмче хуҗалыкларның, совхозларның барлык работникларын, партия, профсоюз оешмаларын бу сугышчан бурычларны большевикларча үтәүгә чакырдылар.

Киңәшмә ярдәмче хуҗалыкларның барлык работникларына махсус мөрәҗәгать кабул итте.

Быел югары уңыш алу өчен большевикларча көрәшик!

Ярыш киң җәелә

САБА. (Телефон буенча). Районның барлык колхозларында да иптәш Сталинның приказын өйрәнүгә багышланган митинглар булып үтте. «Ударник» һәм Ильич истәлеге исемендәге колхозларда үткәрелгән митингта колхозчылар язгы чәчүгә әзерлекне иң кыска вакыт эчендә тәмамлау буенча конкрет йөкләмәләр алып үзара социалистик ярышка чыктылар. Хәзер колхозчылар алган йөкләмәләрен үтәү өчен көрәшәләр.

Ильич истәлеге исемендәге колхоз членнары героик сугышчыларга бүләк итү өчен 2 центнер киптерелгән бәрәңге, 1 центнер киптерелгән чөгендер, 2,5 центнер суган, 100 килограмм ит, 30 килограмм бал, 10 килограмм май җыеп тапшырдылар.

«Правда» колхозы членнары митингта ук Кызыл Армия фондына 16 сарык, «Яңа көч» колхозы членнары 15 сарык, 53 тире, 36 килограмм йон, 5 центнер бәрәңге бирделәр.

«Үзәк» колхозы членнары самолетлар эскадрильясе төзү фондына 95.000 сум акча туплыдылар.

ӘЗЕРЛЕК ЯХШЫ

КАРГАЛЫ, (Телефон буенча). Кызыл Армия районының «Пятилетка» колхозы (председателе иптәш Ефремов) язгы чәчүгә әзерлекне уңышлы алып бара. Сабаннарга, тырмаларга, культиваторларга һәм чәчү машиналарына яхшы сыйфатлы итеп ремонт ясалды. Ремонттан чыккан машиналар акт белән кабул итеп алынды. Камыт, дилбегә, постромка баулары да җитәрлек. 500 гектар мәйданда кар тотылды, басуга 1.078 йөк тирес чыгарылды. 75 центнер көл, 18 центнер кош тизәге җыелды.

Агротехника укуларына 112 кеше катнаша. Түгәрәкнең 4 тапкыр занятиесе булды инде. Колхозчылар үз хуҗалыкларыннан колхоз өчен 35 центнер бәрәңге орлыгы бирделәр.

Тракторчының булышлыгы

Усадьбадагы трактор янында, үзара сөйләшә-сөйләшә, 3 кыз килеп туктады. Аларның берсе алгарак чыкты да:

— Без корыч атның аерым частьларын өйрәндек, аларның тракторның кайсы өлешендә, ни өчен кулланылуларын беләбек инде. Хәзер шуларны хәрәкәткә китереп карыйк, —дип җиңел генә итеп трактор руленә менеп утырды. Бу кыз, 1942 нче елгы авыл хуҗалыгы эшләре вакытында еллык планны 200 процент итеп үтәве һәм 535 килограмм ягулыкка экономия ясаганы өчен Татарстан Верховный Советы Президиумының мактау грамотасы белән бүләкләнгән тракторчы Гаян иптәш Динмөхәмәтова иде.

Бондюг МТС ының алдынгы тракторчысы иптәш Динмөхәмәтова алдагы җәйдә тагын да зуррак уңышларга ирешү өчен үзенең тәҗрибәләрен арттыру өстендә эшли. МТС тагы кызлардан тагын ике кешене тракторчы булырга әзерли. Ул аларны тракторның төзелеше һәм аның аерым частьлары белән таныштырды инде. Хәзер, булачак яшь тракторчыларны машинаны хәрәкәткә китерү юллары белән таныштыра башлады.

АГРОНОМИЯ КИҢӘШЛӘРЕ

КОРИАНДР

Очкак майлар (летучие масла) халык хуҗалыгында гаять әһәмиятле урын тоталар. Ул майлар кондитер һәм парфюмерия промышленностенда аеруча күп кулланылалар, шулай ук төрле дарулар әзерләгәндә дә бик кирәкле әйбер булып исәпләнәләр.

Кориандр—шундый май бирүче культураларның берсе. Аның орлыкларында 13—14 процент гади май һәм 1 процент очкак май бар. Кориандр түбе—терлек өчен бик яхшы азык.

Кориандр—бер еллык үсемлек. Кыргый хәлендә Закавказьеда һәм Урта Азия республикаларында очрый. Зонт чәчәкле үсемлекләр семьясына керә. Сабаклары туры, 50—70 сантиметр биеклеккә кадәр үсә. Тамыры орчыксыман. Яшел вакытта исе начар (кандала исе килә), ә киптергәч бу ис бетә.

Бу үсемлек һәр гектардан 10—20 центнер орлык уңышы бирә. Ворснеж һәм Винница өлкәләрендә соңгы елларда 25 центнер уңыш алучылар да булды.

Казан авыл хуҗалыгы институтының тәҗрибә кырында күп еллардан бирле безнең тарафтан үткәрелеп килгән тәҗрибәләр, кориандрның безнең республикабызда да уңышлы нәтиҗәләр бирәчәгенә тулы ышаныч тудыра. Кориандр хәтта яңгырлы-салкынча җәйле 1941 нче һәм 1942 нче елларда да Казан авыл хуҗалыгы институты кырларында бик яхшы үсте һәм тәмам тулы өлгереш бирде.

Дөрес, кориандрның биологик үзенчәлекләре һәм аңа карата кулланыла торган агротехника алымнары җентекләп өйрәнелмәгән әле. Шулай да, турыдан-туры производствода тупланган тәҗрибәләрдән чыгып, бу әһәмиятле культураны игүгә карата кайбер киңәшләр бирергә була.

Кара туфракның комсыл һәм балчыксыз төрләре кориандр өчен иң яхшы туфрак булып исәпләнә. Шулай ук безнең күзәтүләребез күрсәтүенчә, ул көлсуланган балчыксыл туфракта да яхшы үсә. 1935, 1937 һәм 1942 нче елларда җәй яңгырлы булды. Шуңа да карамастан, кориандр тәмам өлгерде. Димәк, бу культура һава температурасы режимына карата да артык зур таләпчән түгел.

Көз көне чәчеп калдырыла торган культуралар һәм тамыразыклар кориандр өчен иң яхшы элгәр булып исәпләнәләр.

Агротехника алымнары турында кыскача түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин.

Кориандр чәчеләсе участокны аннан элекке культура җыеп алынгач та лущить итәргә, аннан соң сөрү катлавының тулы тирәнлегенә алты төрәнле сабан белән иртә сроктә тунга сөрергә кирәк. Язга чыккач та бу җир шулай ук соңга калдырмастан тырмалана һәм тигезләнә.

Күпчелек хәлләрдә кориандрга тулы минераль ашлама яки калий катнаш фосфорит ашлама бирәләр.

Бу культура иртә игелә торган культуралар белән бер вакытта чәчелә һәм югары уңыш мастерлары яз көне иң иртә срокта чәчүне хәлиткеч чара дип исәплиләр. Чәчү алдыннан орлыклар 25 градус җылылыкта 12 көн чамасы яровойлаштырылалар. Яровойлаштыру өчен һәрбер центнер орлыкка 60 литр чамасы су сибелә. Рәт аралары 30—32 сантиметр булганда һәр гектарга 12—14 килограмм орлык җитә.

Орлыкны күмдерү тирәнлеге—1—2 сантиметр.

Орлыкның үсүе һәм шытым бирүе чорында туфрак өстенең кабыкланып катуы кориандр өчен аеруча куркыныч. Бу куркыныч булмасын өчен рәтләргә ярты сантиметр калынлыкта һәм 10 сантиметр киңлектә чәрмә яки туфрак катнаш торф сибәләр. Бу чара бер яктан туфракның өстен кабыкланудан саклый һәм орлык шытым биргәнчегә кадәр үк рәт араларын йомшартырга мөмкинлек бирә. Чәчкәннән соң орлыклар озак тиешелә алмый торсалар һәм туфрак өсте кабыкланып катса, мондый участокларны гади тырмалар белән кичекмәстән тырмаларга кирәк.

Рәт аралары җәй буенча 4—5 тапкыр йомшартыла. Рәтләрдәге чүп үләннәр утала, ләкин башка кайбер культуралар шикелле кориандрга карата сирәкләү үткәрелми. Үсүнең баштагы фазасында кориандрны фосфорлы ашлама белән тукландырырга киңәш бирелә.

Кориандр акрын җитлегүе белән характерлы. Аның орлыкларында эфир мае орлык каты башлау фазасында күбрәк була. Шуңа күрә бу моментны кориандрның техник өлгереш фазасы дип исәплиләр һәм аны шул вакытта җыялар. Җыю өчен гади урак машиналарыннан һәм комбайннардан файдаланалар.

Яңа культураларга, шул исәптән кориандрга җитди әһәмият бирергә һәм безнең шартларда яңа культура булуына карамастан аның да быел ук югары уңыш бирүе тәэмин ителергә тиеш.

Р. ХӨСӘЕНОВ,

Казан авыл хуҗалыгы институты доценты.

ЯҢА ҖИҢҮЛӘР ӨЧЕН

Дөбьяз МТС коллективы иптәш Сталинның котлау телеграммасын алып укыгач, Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә оештырылган Бөтенсоюз социалистик ярышка кушылып яңа йөкләмәләр алды.

Ремонт эшчеләре алган йөкләмәләрен намус белән үтәү өчен барлык көчләрен биреп эшлиләр. Моторларга ремонт ясау узелы бригадиры иптәш Мәгъсумов, моторларны сүтү эшендә Нәбиуллина, арткы күперләрне ремонтлауда Стрикалова иптәшләр аеруча яхшы эшлиләр. Болар көнлек нормаларын арттырып үтиләр.

Ремонт эшләрен оештыруда МТС ның өлкән механигы иптәш Яшин аеруча яхшы эшли. Аның инициативасы белән күп кенә частьлар яңадан эшләнделәр, искеләре реставрацияләнделәр. Әгәр дә узган ел бу вакытка (15 нче январь), бер трактор да ремонттан чыкмаган булса, быел 15 нче январьга 22 трактор, 31 арткы күпер, 26 мотор, 11 чәчү машинасы, 10 культиватор, 10 сабан, 8 лущильник, 11 чәчү машинасы ремонттан чыкты инде.

МТС та тагылма инвентарьларга ремонт ясауны Кызыл Армиянең XXV еллыгына 100 процентка тәгәлләү өчен сугышчан көрәш алып барыла.

З. КАРАМОВ,



Калинин шәһәре урамнарында
ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТЛАР СОЮЗЫНДА

АЗАТ ИТЕЛГӘН РАЙОННАРНЫҢ КОЛХОЗЛАРЫНА ЧӘЧҮ ОРЛЫКЛАРЫ

Иваново өлкәсенең хезмәт ияләре азат ителгән районнарның колхозлары өчен чәчүлек орлык җыя башладылар. Палех районының колхозлары 30 нчы январьга 1.300 пот чәчүлек орлык җыйдылар. Гаврилово-Посадский районында 1.600 пот орлык җыелды.

Күп кенә колхозларның председательләре беренчеләр булып үз хуҗалыкларындагы запастан 100 пот орлык билгеләп куйдылар.

Азат ителгән районнар өчен орлык һәм ул районнарның хезмәт ияләре өчен азык җыю торган саен киңрәк җәелә бара.

АШХАНӘЛӘР ЯНЫНДА ЯШЕЛЧӘ ҮСТЕРҮ

«Ленглавресторан» тресты ашханәләрендә иртә өлгерә торган яшелчәләрне бүлмәләрдә үстерү оештырылды. Салат, яшел суган, укроп үстерү өчен ярдәмче биналарда 3.000 квадрат метр күләмендә мәйдан билгеләнде. Яшелчәләр яхшы ашланган туфрак тутырылган тартмаларга утыртылалар. Күп кенә ашханәләрдә инде беренче уңыш та җыеп алынды.

ЯРАЛЫ СУГЫШЧЫЛАР ТУРЫНДА КАЙГЫРТУЧАНЛЫК

Татарстандагы күп кенә районнарның колхозчылары госпитальләрне сөт белән тәэмин итәләр. «Строитель» колхозы членнары яраланган сугышчылар өчен колхозның фермасыннан ел буена 30 мең литр сөт бирергә карар бирделәр. Ленин исемендәге колхоз членнары 10 мең литр сөт бирәчәкләр. (ТАСС).

УСМАН ӘЛМИЕВ КОНЦЕРТЫ

1 нче февральдә Татар дәүләт академия театры бинасында Усман Әлмиевнең концерты булды. Сәнгатьнең яшь һәм талантлы бу работнигы үзенең концертын «Совет актеры» исемле танклар колоннасы төзелеше файдасына багышлады. Гадәттә була торган бик күп концертлардан ул нык әнә шуның белән аерыла да.

Казан хезмәт ияләре тарафыннан аеруча яратылып тыңлана һәм карала торган актерларның берсе—У. Әлмиев иптәшнең концерты үзен тулысынча аклады. Концерт энергияле төстә һәм зур темперамент белән үтте, үтәлгән һәрбер номер тамашачыда тирән тәэсир калдырды һәм зур канәгатьләнү тудырды.

Концерт 2 бүлектән торды. Беренчесендә бөек ватан сугышына багышланган әсәрләр, ә икенчесендә—халык көйләре һәм музыкасы башкарылды. Татар совет композиторларыннан С. Сәйдәшев, Җ. Фәйзи, Ключарев иптәшләрнең башкарылган әсәрләре тамашачылар тарафыннан аеруча зур игътибар белән тыңланганлыгын әйтергә кирәк.

Концертның уңышлы чыгуына композитор Заһид Хәбибуллин, рояль партиясен алып баручы Лидия Фукс һәм конферансье Маһинур Шарипова иптәшләр дә үзләренең тырышлыклары белән шактый дәрәҗәдә ярдәм иттеләр.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР НЕМЕЦ ФАШИСТЛАРЫНЫҢ СТАЛИНГРАД РАЙОНЫНДА ЧОЛГАНЫП АЛЫНГАН ГАСКӘРЛӘРЕН БЕТЕРҮНЕ ТУЛЫСЫНЧА ТӨГӘЛЛӘДЕЛӘР

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

командующие генерал-майор РАСКЕ, 7) генерал-майор МАГНОС.

Шулай ук генерал-фельдмаршал ПАУЛЮСНЫҢ личный адъютанты полковник АДАМ, 14 нче танк дивизиясе командиры полковник ЛЮДВИГ, 100 нче пехота дивизиясенең 227 нче пехота полкы командиры полковник ФРАНЦ НАЙБЕККЕР, 2 нче миномет полкы командиры ФРИДРИХ НАЙЕР, 29 нчы мотодивизиянең 29 нчы артиллерия полкы командиры ГЮНТЕР КРАГ, 8 нче армия корпусы штабы начальнигы полковник ШНИТЦЕР, румыннарның 1 нче кавалерия дивизиясенең артиллерия начальнигы полковник МАЛЬТОПОЛЬ, 8 нче армия корпусының 13 нче сапер полкы командиры полковник ШИЛЛЕНГ, 76 нчы пехота полкының штаб начальнигы полковник БЕЛОГУЛАТ, 48 нче аерым элемтә полкы командиры полковник КАРЕНЕЦКИЙ, 376 нчы пехота дивизиясенең 51 нче артиллерия полкы командиры полковник ШВАРЦ, 44 нче пехота дивизиясенең 134 нче пехота полкы командиры полковник БОЙЕ, 376 нчы артиллерия полкы командиры полковник ФУР, 376 нчы пехота дивизиясенең 576 нчы пехота полкы командиры полковник ШИТЕЗЕНФ, 37 нче артиллерия полкы командиры полковник ВОЛЬТ, 44 нче пехота дивизиясенең 134 нче артиллерия полкы командиры полковник БОСАРТУР, 376 нчы пехота дивизиясенең 536 нчы пехота полкы командиры полковник ШЛЕЗИНГЕР, 627 нче артиллерия полкы командиры полковник БЕРЕНЕК, 767 нче пехота полкы командиры полковник ШТЕЙДЛЕ, 14 нче танк дивизиясенең штаб начальнигы фон ВОЛЬТ, 76 нчы пехота дивизиясенең штаб начальнигы полковник БРИДГУЛЬЦ, 54 нче пехота полкы командиры полковник ЛЕБЕР, полковник врач КАЙЗЕР, 297 нче пехота дивизиясенең 523 нче пехота полкы командиры полковник ГАНС ЛИБАУ һәм күп кенә башкалар плен алынды.

Сталинград янында булган сугышларда безнең гаскәрләр барлыгы 24 генералны һәм 2.500 дән артык офицерны плен алдылар.

Дошманның чолганып алынган гаскәрләренә каршы генеральный һөҗүм вакытында, 10 нчы январьдан 2 нче февральгә кадәр, тулы булмаган саннарга караганда безнең гаскәрләр түбәндәге трофейларны кулга төшерделәр: самолетлар—750, танклар—1,550, орудиеләр—6.700, минометлар—1.462, пулеметлар—8.135, винтовкалар—90.000, автомашиналар—61.102, мотоцикллар—7.369, тягачлар, тракторлар, транспортерлар—480, радиостанцияләр—320, бронепоездлар—3, паровозлар—56, вагоннар—1.125, сугыш припаслары һәм кораллар тутырылган складлар—235 һәм бик күп кенә санда башка төрле сугыш милекләре. Трофейларның санын алу дәвам итә.

Сугышлар тарихында булган иң зур сугышлардан берсенең нәтиҗәсе шундый.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Совет информбюросыннан

2 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

2 нче февральгә каршы төндә **Көньяк-Көнбатыш, Көньяк, Төньяк Кавказ, Закавказье, Воронеж, Ленинград** һәм **Волхов** фронтлары гаскәрләре элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Сталинградтан көнбатыштарак Дон фронты гаскәрләре дошманның каршылык күрсәтүче таркатылган группаларын кыруны дәвам иттерделәр. Дошманның терәк пунктларына артиллериядән атып торганнан соң Н-че часть сугышчылары дошманның күп кенә ДЗОТ ларын һәм блиндажларын алдылар. Пленныйлар алынды.

* * *

Көньяк фронт гаскәрләре һөҗүм сугышлары алып бардылар. Мечетинская районында немецлар, безнең частьларны тоткарларга маташып, бик нык каршылык күрсәттеләр. Бу участокта немецларның каршылык күрсәтүе бастырылды һәм алар безнең гаскәрләрнең ударлары астында чигенәләр. Совет сугышчылары халык яши торган ныгытылган берничә пунктны алдылар, 3 танк һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Көньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре һөҗүмне дәвам иттерделәр. Бер участокта дошман чигенгән чакта сугыш кырында 300 дән артык солдат һәм офицерларының үле гәүдәләрен калдырды. Н-че часть сугышчылары халык яши торган бер пунктны алдылар һәм 13 пулемет, 5 миномет, бер азык склады һәм күп кенә сугыш припаслары кулга төшерделәр.

* * *

Воронеждан көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктны алдылар. Н-че часть немецларның бер батальонын чолгап алып, аны бөтенләе белән пленга алды. Безнең танкистлар, чигенүче дошманны куып барып, дошманның 13 орудиесен, 21 автомашинасын юк иттеләр һәм 129 немец солдатын һәм офицерын плен алдылар. Икенче бер участокта 15 орудие, 150 автомашина һәм башка төрле сугыш милекләре кулга төшерелде. 450 дошман солдаты һәм офицеры плен алынды.

* * *

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре уңышлы рәвештә алга бардылар. Н-че берләшмә частьлары 38 танк, 270 автомашина, сугыш припаслары, азык, медикаментлар һәм төрле сугыш милекләре төялгән 196 вагон кулга төшерделәр. Икенче бер участокта безнең сугышчылар халык яши торган бер пунктны алган чакта күп кенә трофейлар кулга төшерделәр. Шулар арасында 3 танк, 13 автомашина, снарядлар төялгән 4 вагон, авиация бомбалары төялгән 6 вагон, азык төялгән бер эшелон һәм 700 баш мөгезле эре терлек бар.

* * *

Могилев өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды ике атна эчендә дошманның 14 хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Һәлакәт нәтиҗәсендә бик күп гитлерчылар үлгән һәм яраланган. Шуның өстенә совет патриотлары 10 күперне шартлатканнар, 42 автомашинаны яндырганнар һәм җимергәннәр. Партизаннар бер орудие, 144 винтовка, 120 снаряд, 10 мең патрон һәм башка төрле сугыш милекләре кулга төшергәннәр.

* * *

Венгерларның 9 нчы пехота дивизиясенең 17 нче полкыннан плен алынган солдат Митро Рудаш болай диде: «24 нче январьда немецларның 57 нче пехота дивизиясенең 164 нче полкы командиры подполковник Ленц приказы буенча Кочетовка авылында 49 венгер офицерын пленга бирелергә тырышкан өчен атып үтерделәр». Немецларны Кочетовка авылыннан куганнан соң Рудашның бу сүзләренең дөреслеге тикшерелде. Аның әйткәннәре тулысынча расланды. Атып үтерелгән венгер офицерларының үле гәүдәләре табылды. Хәзер аларның фамилияләре эзләнә.

* * *

Түбәндә Воронеж өлкәсе, Истобное авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Немецлар изүе астында чакта без бик күп газаплар һәм авырлыклар кичердек. Немец юлбасарлар, авылга бәреп кергәннән соң беренче көнне үк 18 кешене атып үтерделәр. Шуннан соң талаулар башланды һәм алар оккупациянең соңгы көненә кадәр дәвам иттеләр. Немецлар безнең 250 сыерыбызны, вак терлекләребезне, барлык йорт кошларын, бөтен ашлыкны, аяк һәм өс баш киемнәрен талап алдылар. Палачлар колхозчы Тимофей Крепишинны, аның кызын һәм баласының баласын атып үтерделәр, ә Крепишинның карт анасын тере көе яндырдылар. Чигенер алдыннан фашист ерткычлар бер группа картларны һәм хатын-кызларны «Память Ленина» колхозының терлек дворына куып керттеләр һәм аларга гранаталар ыргыттылар. Күп колхозчылар һәлак булды. Гитлерчылар безнең авылда барлыгы 56 кешене газаплап үтерделәр һәм 80 колхозчы хатын-кызны Германиягә каторга эшләренә алып киттеләр». Актка Истобное авылы кешеләреннән Н. Аксенов, А. Ватутин, С. Зубарев, П. Захарова һәм М. Семеновалар кул куйды.

2 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

Дон фронты гаскәрләре немец фашистларының **Сталинград** районында чолганып алынган гаскәрләрен бетерүне тулысынча тәмамладылар. 2 нче февральдә Сталинградтан төньяктарак булган районда дошманның каршылык күрсәтә торган соңгы үзәге сытып ташланды. Сталинград янында булган тарихи сугыш безнең гаскәрләрнең тулы җиңүе белән тәмам булды.

Сватово районында безнең гаскәрләр район үзәкләре **Покровскоены** һәм **Нижняя Дуванканы** алдылар.

Тихорецк районында безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, район үзәкләреннән **Павловскаяны, Ново-Леушковскаяны, Кореновскаяны** алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар.

Баренц дингезендә безнең корабльләр дошманның 12.000 тонна авырлыкта бер транспортын батырдылар.

* * *

1 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 5 артиллерия батареясының утын бастырдылар һәм ике батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Көньяк фронт гаскәрләре, гитлерчыларның контратакаларын кире кайтарып, алга баруларында дәвам иттеләр. Н-че берләшмә сугышчылары дошманны халык яши торган күп кенә пунктлардан бәреп чыгардылар һәм дошманны зур югалтуларга дучар иттеләр. Халык яши торган бер пункт районында гына да немец солдатларының һәм офицерларының 300 дән артык үле гәүдәләре калды. Икенче бер участокта дошман пехотасы һәм танклары, югалткан позицияләрен кайтарып алырга маташып, ике тапкыр контратакага күчтеләр. Сугыш нәтиҗәсендә немецлар 4 танкларын югалттылар һәм берничә дә уңышка ирешә алмыйча чигенделәр.

* * *

Сватово районында безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм операцияләре алып бардылар. Халык яши торган бер зур пункт өчен булган сугышларда безнең частьлар немецларның 28 танкысын, 22 орудиесен һәм күп автомашиналарын юк иттеләр. Шулай ук дошманның 4 самолеты атып төшерелде. 6 кыр орудиесе, 3 самоход пушка, 35 автомашина, 2 сугыш припаслары склады кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең танкистлар 200 немец солдатын һәм офицерын кырдылар, 120 кешене плен алдылар. 2 танк, йөк төялгән 10 автомашина һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Воронеждан көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә алга бардылар.

Иптәш Ефимов командалык итә торган часть немецларның бер пехота полкын җимерде. 300 дошман солдаты һәм офицеры пленга бирелде. Икенче бер участокта Н-че берләшмә сугышчылары бер көн эчендә 500 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын плен алдылар. Бик күп трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары бер көн эчендә халык яши торган 6 пунктны алдылар. Немецлар тарафыннан көчле рәвештә ныгытылган бер терәк пункты янында бик каты сугыш булды. Совет сугышчылары фронттан һөҗүм итеп дошман гарнизонын хәрәкәтсез калдырдылар. Шул арада безнең башка подразделениеләребез дошманны әйләнеп үттеләр һәм аңа флангылардан һәм тылдан атака ясадылар. Немецлар гарнизоны бөтенләй диярлек юк ителде. Сугыш припаслары, снаряженнеләр һәм азык тутырылган складлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта Н-че частьның хәрәкәттәге отряды дошман тылына барып чыкты һәм немецларның бер артиллерия батареясын, 12 пулеметын, 4 миномётын һәм бер миналар складын кулга төшерде.

* * *

Смоленск өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды бер атна эчендә дошманның 5 хәрби эшелонын юлдан чыгарган. 2 паровоз, 41 вагон һәм 13 платформа җимерелгән. 950 метр озынлыкта тимер юл бозылган. Смоленск партизаннарының икенче бер отряды немецларның фронт линиясенә килә торган бер обозына һөҗүм иткән. Партизаннар 8 мичкә бензинны яндырганнар, 23 ат һәм берничә мең патрон кулга төшергәннәр.

* * *

Түбәндә Воронеж өлкәсенең Солдатское авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Гитлерчылар, Ленин исемендәге һәм Буденный исемендәге колхозларның бөтен иген уңышын талап алдылар, колхозчыларны таладылар һәм ачтан үлүгә дучар иттеләр. Фашист бандитлар тирә-як авыллардагы халыкны бөлдерделәр һәм барлык колхозчыларны Солдатское авылына куып китерделәр. Араларында бик күп хатын-кызлар һәм балалар да булган 11.000 ләп кеше ат абзарларында, сарайларда һәм землянкаларда тордылар. Немецлар аларны ач тоттылар һәм бер кая да чагырмадылар. Бераз вакыт үткәч гитлерчылар бу газапланган һәм хәлсезләнгән кешеләрне көнбатышка тагын да ераккарак кудылар. Фашист ерткычлар авыруларны һәм ачлыктан хәлсезләнгәннәрне юлда атып үтерделәр. Фашист палачлар авылда 11 пленный кызылармеецны астылар һәм 30 яшьлек Анна Анцупованы, 25 яшьлек Анна Пальчиковaны, 35 яшьлек Ольга Попованы, 70 яшьлек Федор Зыковны һәм башка кешеләрне атып үтерделәр. Авылдан чигенгән чакта немецлар җәмәгать биналарын һәм колхозчыларның 30 йортын яндырдылар». Актка И. Золотухин, И. Мочнев, М. Попов һәм авыл советы председателе Емельяновлар кул куйды.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Зур драма театры. Бүген — *„Фронт“*, 4 нче һәм 5 нче февральдә—*„Маскарад“*.

Яшь тамашчылар театры. Бүген һәм 4 нче, 5 нче февральдә—*„Москвичка“*. Кич 7 сәгатьтә башлана.

Дәүләт циркы. Бүген—*зур цирк тамашасы* һәм французча көрәш ярышлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

„Электро“ — музыкаль комедия *„Антоша Рыбкин“*

„Унион“—*„Котовский“*

„Пионер“ көндез—*3 нче номерлы Кино-сборник*, кич — *„Чайковский“*.

„Чатки“—*„3 мушкетер“*.

ПФ28. „Красная Татария“ һәм „Кызыл Татарстан“ издательствосының Александров исемендәге типографиясе № Заказ 189